# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Транспорт салымы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы үз көчен югалткан дип танырга;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Транспорт салымы (алга таба – салым) Россия Федерациясе Салым кодексы һәм әлеге Закон белән билгеләнә һәм әлеге Закон белән гамәлгә кертелә.

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым ставкалары, аны түләү тәртибе һәм вакытлары, шулай ук салым ташламалары һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләре билгеләнә.»;

3) 2, 3 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 5 статьядагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:»;

5) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 8 статьядагы 2 пунктта:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Физик затлар булган салым түләүчеләр салымны үткән салым чорыннан соң килә торган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча түлиләр.»;

б) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 26 ноябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 11);

2) «Татарстан Республикасының транспорт салымы турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11);

3) «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 6 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктының бишенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч, ләкин транспорт салымы буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 73-ТРЗ